Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАРЫ

КАРАРЫ

01.07.2022 ел. Менделеевск ш. №123

Менделеевск муниципаль районы территориясендә 2022 елның җәйге чорында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында

«Менделеевск районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ директоры Е.Н.Мөхәммәдиеваның җәйге чорда Менделеевск муниципаль районы территориясендә балигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы җәйге чорда яшүсмерләрне эш белән тәэмин итүне оештыру җирле үзидарә органнарының өстенлекле бурычларының берсе булуын билгеләп үтә. Балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруның төп максаты - балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау, аларның иртә профориентациясе, аз керемле гаиләләрдән булган яшүсмерләргә, шулай ук социаль куркыныч хәлдәге гаиләләргә социаль һәм матди ярдәм күрсәтү. Яшьләрнең хезмәт базарына яхшы керүенә ярдәм итә.

Җәйге чорда балигъ булмаганнарның хезмәт эшчәнлеген оештыру чаралары «2022 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, эш белән тәэмин ителешен оештыру турында» Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 31 гыйнварындагы 52 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла. 2022 елда 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге 185 балигъ булмаган гражданны эшкә урнаштыру планлаштырыла. Агымдагы елның 1 июненнән 72 яшүсмер эшкә урнаштырылган.

Шул ук вакытта, барлык теләүче балигъ булмаганнарны хезмәткә максималь җәлеп итү максатыннан, җәйге чорда яшүсмерләрне вакытлыча эшкә урнаштыру өчен эш урыннары булдыручы эш бирүчеләрне җәлеп итү эшен активлаштырырга кирәк.

Балигъ булмаганнарны хезмәткә катнаштыруда, һөнәри күнекмәләр алуда һәм хезмәт эшчәнлегенә яраклашуда, аларда социаль куркыныч тәртип модельләрен формалаштыруны булдырмауда яшүсмерләр өчен вакытлы эш урыннары булдыруның аерым социаль әһәмиятен исәпкә алып,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. «Менделеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ директоры Е.Н. Мөхәммәдиеваның 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны җәйге чорда вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турындагы мәгълүматын җәйге чорда Менделеевск муниципаль районы территориясендә игътибарга алырга.

2. «Менделеевск муниципаль районы мәгариф идарәсе" МКУнә:

- район гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары арасында балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнашуга ихтыяҗны ачыклау эшен дәвам итәргә;

- балигъ булмаган гражданнарны эшкә урнаштыру мәсьәләсе буенча укучыларның ата-аналары белән аңлату эшләре алып барырга;

- Менделеевск районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге, ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге «Менделеевск районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ белән берлектә, 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны , шулай ук социаль куркыныч хәлдә булган , профилактик исәптә торучы балигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыруда ярдәм итәргә.

3. Менделеевск муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләренә:

- эшләмәүче һәм укымаучы балаларны исәпкә алуны һәм исемлеген төзүне тәэмин итәргә;

- балигъ булмаган гражданнарның хезмәт шартларын башка вәкаләтле органнар белән үзара хезмәттәшлектә системалы тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

- ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, аз керемле, күпбалалы һәм тулы булмаган гаиләләрдәге балаларга, инвалид балаларга, яшүсмерләргә, профилактик исәптә торучы яшүсмерләргә, тәрбия колониясеннән яки махсус укыту-тәрбия учреждениеләреннән кайткан яшүсмерләргә вакытлыча эшкә урнашуда ярдәм күрсәтергә.

4. “Менделеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ДБУне җәйге чорда яшүсмерләрне вакытлыча эшкә урнаштыру өчен эш урыннары булдыручы эш бирүчеләрне җәлеп итү эшен активлаштырырга тәкъдим итәргә.

5. Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты матбугат хезмәте балигъ булмаганнарның җәйге хезмәт мәшгульлеген массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Менделеевск муниципаль районының социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча даими комитет утырышында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны эшкә урнаштыру буенча җирле үзидарә органнарының эш йомгакларын карарга (срогы - 2022 елның 15 сентябренә кадәр).

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары: Л.К.Галиева